ГЛАВА БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.


ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30.10.2023 — 4

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Татарское Бурнашево

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы  авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы  Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының районының Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы гражданнары арасында 2023 елның 13 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны  расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлегенең Татар Борнашы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
   - Татар Борнашы авылында юлларга асфальт валчык салу

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Татар Борнашы авылы, Совет урамы, 58 нче йорт адресы буенча 13.00 сәгатьтә гражданнар җыенын уздырырга.
4. Борнаш авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин